**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.06.2019 № 04-05-59

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы сатып алулар буенча дәүләт комитетының Иҗтимагый советы турында Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 2016 елның 23 мартында 04-14-41нче номерлы боерыгы белән расланган Положениега үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының министрлык, дәүләт комитеты, ведомство каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендә кабул ителгән 906нчы номерлы карарына ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы сатып алулар буенча дәүләт комитетының Иҗтимагый советы турында Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 2016 елның 23 мартында 04-14-41нче номерлы боерыгы белән расланган Положениега (Татарстан Республикасы сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 12 маенда кабул ителгән 04-14-64нче һәм 2017 елның 9 ноябрендә кабул ителгән 04-14-162 нче номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның дүртенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«җәмгыятьтә коррупциягә бәйле хәлләргә карата тискәре караш формалаштыру.»;

5.12 пунктның икенче җөмләсен алып атырга.

2. Шушы карарның үтәлешен контрольда тотуны Татарстан Республикасының сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары М.С. Ротарьга йөкләргә.

Рәис О.А.Редько